| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.11.2023 г. Казань № 373-5/нпс-2023

Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләренщ техник тикшерүләр үткәрү, шулай ук сатылган яки ремонтланган техниканың сыйфаты тиешенчә булмау сәбәпле күзәтчелектәге машиналар һәм җиһазлар хуҗаларының дәгъваларын карау буенча комиссияләрдә катнашу буенча хезмәтләр күрсәткән өчен җыемнар күләмен билгеләү турында

«Транспорт чараларын техник карау һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 1 июлендәге 170-ФЗ номерлы федераль законга, Министрлар Советы – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә үзйөрешле машиналарның һәм техниканың башка төрләренең техник торышына дәүләт күзәтчелеге турында» 1993 елның 13 декабрендәге 1291 номерлы карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 15.11.2023 № 48-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасына ярашлы рәвештә үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләренщ техник тикшерүләр үткәрү, шулай ук сатылган яки ремонтланган техниканың сыйфаты тиешенчә булмау сәбәпле күзәтчелектәге машиналар һәм җиһазлар хуҗаларының дәгъваларын карау буенча комиссияләрдә катнашу буенча хезмәтләр күрсәткән өчен җыемнар күләмен билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Тракторларның, үзйөрешле юл-төзелеш һәм башка төрле машиналарның һәм аларга тагылма арбаларның техник торышына, шулай ук агросәнәгать комплексында машиналарны һәм җайланмаларны эксплуатацияләү кагыйдәләренең

үтәлешенә дәүләт күзәтчелеген үткәргәндә хезмәтләр күрсәтү өчен җыемнар күләмен билгеләү хакында» 23.12.2016 №7-22/т карарын көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.11.2023 № 373-5/нпс-2023
карарына кушымта

Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләренщ техник тикшерүләр үткәрү, шулай ук сатылган яки ремонтланган техниканың сыйфаты тиешенчә булмау сәбәпле күзәтчелектәге машиналар һәм җиһазлар хуҗаларының дәгъваларын карау буенча комиссияләрдә катнашу буенча хезмәтләр күрсәткән өчен җыемнар күләме

| т/с | Җыемнар күләменең аталышы | Җыем күләме, сум/берәмлек |
|---|---|---|
| 1. | Машиналарга һәм аларның тагылма арбаларын техник карау | 500,0 |
| 2. | Күзәтү машиналары һәм җайланмалары хуҗаларының сатылган яки төзекләндерелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавы турындагы ризасызлыкларын карап тикшерү комиссияләрендә катнашу | 350,0 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге